**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «КНЯЗЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«24» сентябрь, 2019 ел «Татарстан» совхозы пос. № 9/3

Князево авыл җирлегендә җирле референдум үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 маддәләре, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20, 35 маддәләре, «Җирле референдум турында» 2004 елның 25 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 маддәсе, Князево авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 24 сентябрендәге 119 номерлы карары, Князево авыл җирлеге Советының 2019 елның 24 сентябрендәге 9/2 номерлы карары, Князево авыл җирлеге уставы нигезендә

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2019 елның 8 декабренә якшәмбе көнгә Князево авыл җирлегендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Князево авыл җирлеге Башкарма комитеты белән берлектә Князево авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү турында инициативаны чыгарырга, җирле референдум сорауларын түбәндәгечә формалаштырырга:

«2020 елда яшәү урыны буенча Князево авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- «Татарстан» совхозы поселогында янгын депосы төзү;
- «Татарстан» совхозы поселогында, Князево, Казиле, Чыршылы авылларында, Сосновый Бор поселогында юлларны төзекләндерү;
- вак таш, асфальт валчыгы сатып алу һәм «Татарстан» совхозы поселогында, Князево, Казиле, Чыршылы авылларында, Сосновый Бор поселокларында юлларга салу;
- энергия саклаучы лампалар сатып алу һәм «Татарстан» совхозы поселогында, Князево, Казиле, Чыршылы авылларында, Сосновый Бор поселогында урнаштыру;
- «Татарстан» совхозы поселогында паркларны төзекләндерү;
- балалар мәйданчыклары сатып алу һәм «Татарстан» совхозы, Сосновый Бор поселокларында урнаштыру;

- Сосновый Бор поселогында суүткәргеч челтәрен ремонтлау;

- «Татарстан» совхозы поселогында мөселман зираты тирәли дренаж системасын урнаштыру;

- Князево авыл җирлеге территориясендә рөхсәт ителмәгән чүплекләрне юк итү?».

3. Референдумны әзерләү һәм үткәрүне референдум комиссияләренә йөкләргә:

- муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә (Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясе);

- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Князево авыл җирлегенең участок сайлау комиссияләре.

4. Җирле референдум үткәрү белән бәйле чыгымнарны Князево авыл җирлеге бюджеты средстволары хисабына гамәлгә ашырырга.

5. Әлеге карарны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырырга.

6. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмати стендларында һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе

Т.И. Белова